Татар мәктәбендә укучы балаларга татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр

8 нче сыйныф 2016-2017 уку елы

**Үткәрү вакыты- 90 минут** **Максималь балл – *66***

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1.Борын тартыкларының барысы да кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Мин базардан карбыз, кавын һәм кыяр сатып алдым.

ә) Кыш көне балалар чана, чаңгы шуарга яраталар.

б) Мәктәп ишекләре киң итеп ачылган.

в) Миләүшә белән Ләйсән – 8нче сыйныф укучылары.

2. Җөмләдәге ирен гармониясе күзәтелгән сүзләр санын билгеләгез. ***(2 балл)***

*Димәк, дус кошын дүрт-биш көн эчендә эзлексез әңкә кошны чакырган. (Г.Хәсәнов)*

а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5.

3. Нигез төрләре дөрес күрсәтелмәгән сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Башла, көрәк, җилкуар, иртә-кич, сабан туе.*

а) ясалма, ясалма, кушма, парлы, тезмә; ә) тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә;

б) тамыр, тамыр, кушма, парлы, тезмә; в) тамыр, ясалма, кыскартылма, парлы, тезмә.

4.Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең фразеологик вариантын билгеләгез. ***(2 балл)***

*Рәмзия имтиханнар алдыннан бик нык **борчыла**.*

а) чыраен сыта; ә) ут йота; б) тәлинкә тота; в) кул кушырып утыра.

5. Яңа сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) почта, рәис, директор; ә) китап, телевизор, компьютер;

б) флешмоб, коуч, магистр; в) факс, оешма, флешка.

6. ***Өчпочмаклы*** сүзенең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. ***(2 балл)***

а) сан; ә) алмашлык; б) сыйфат; в) исем.

7. ***Шул, һичкайда, бөтен, аларныкы, кайбер*** алмашлыкларының төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) күрсәтү, юклык, билгеләү, тартым, билгесезлек;

ә) билгеләү, юклык, күрсәтү, зат, билгесезлек;

б) тартым, юклык, күрсәтү, зат, сорау;

в) күрсәтү, сорау, билгеләү, күрсәтү, билгесезлек.

8. ***Кызыл күлмәк*** сүзтезмәсендәге бәйләүче чараны билгеләгез. ***(2 балл)***

а) *-ыл* кушымчасы; ә) фигыль формасы; б) баш килеш формасы; в) сүз тәртибе.

9. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Син идеңме сахраларда*

*Гөлгә кунган күбәләк?* (Җыр)

а) күбәләк; ә) сахраларда; б) кунган; в) син идеңме.

10. Кыек тәмамлык кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Һәр кошның үз тавышы үзенчә матур. (Мәкаль);

ә) Кешенең белемен сүзеннән аңларсың. (Мәкаль);

б) Йөз явызлыкны бер дөреслек җиңә. (Мәкаль);

в) Тел ташны эретә. (Мәкаль).

11. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Ул күрше кызларын үзләренең ишегалдына **уйнарга** чакыра.* (М.Хуҗин)

а) рәвеш хәле; ә) сәбәп хәле; б) максат хәле; в) урын хәле.

12. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Кинәт яңгыр ява башламасынмы?!* (Г.Гыйльманов)

а) сорау, тойгылы, инкяр, бер составлы; ә) хикәя, тойгылы, инкяр, ике составлы;

б) сорау, тойгылы, раслау, ике составлы; в) сорау, тойгылы, инкяр, ике составлы.

**II. Теоретик бирем.**

Аныклагычлар турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. ***(10 балл)***

**III. Грамматик һәм иҗади бирем.**

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне языгыз, түбәндә бирелгән грамматик һәм иҗади биремнәрне үтәгез.

БР ЙГЛГН ВКТ ЙҢДН КТМС. ***(5 балл)***

1. Мәкальдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. ***(5 балл)***
2. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз. ***(5 балл)***
3. Өченче сүзгә фонетик анализ ясагыз. ***(5 балл)***
4. Кайсы сүзләрнең синонимнарын беләсез? Синонимик оя төзеп языгыз. ***(5 балл)***
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(7 балл)***